**Латыйпов, Рәмис** «Кара китап»: Амброзия / Р. Латыйпов. - Текст : турыдан-туры // Шәһри Чаллы. – 2019. – №3 (18 январь). – С.12.
***Төп сүзләр:*** *– Татарстан Республикасы – Куркыныч тудырган үсемлекләр – «Кара китап» – Амброзия – Экология*

Рәмис ЛАТЫЙПОВ

# «КАРА КИТАП»: Амброзия

## Татарстандагы иң куркыныч үсемлек үсемлек - амброзияне еш кына клумбаларда да күрергә мөмкин.

Татарстанның «Кара китабым әзерләү белән шөгыльләнүче КФУның Гомуми биология кафедрасы доценты Вадим Прохоров газета укучыларга үткән санда «Сосновский» балтырганы турында сөйләгән иде. Әмма кешегә һәм табигатькә зыян сала торган үсемлекләр исемлегендә амброзия беренче урынны били. Бу үсемлекнең зыяны нәрсәдә соң?

- Минемчә, амброзия - иң куркыныч үсемлек. Балтырганга караганда да зыянлырак! - ди **Вадим Прохоров.**

Галимнәр үсемлекләр дөньясы - флорага куркыныч тудырган үсемлекләрне «Кара китап»ка кертә.

Мәсәлән, «Сосновский» балтырганының согы тәнгә тигән очракта гына «пешәргә» мөмкин- сең. Әгәр инде аңа кагылмыйча, урап узасың икән,зыяны тимәячәк. Ә амброзия - иң көчле аллерген, чәчәк аткан вакытта аның серкәләре көчле аллергик реакция китереп чыгара. Кешедә поллиноз, яки сезонлы аллергик риноконъюнктивит башланырга мөмкин.

Борынгы грек мифологиясе буенча, амброзия - Аллалар ризыгы, ул кешене яшәртә дип ышанганнар. Ә чынлыкта ул сәламәтлек өчен бик куркыныч. Әлеге үсемлек аркасында яшәү урынын алыштырырга мәҗбүр булалар, чөнки аның серкәсе таралып, кешедә аллергия китереп чыгарса, бернинди дарулар да ярдәм итми. Кайвакыт авыру аллергия сәбәпчесе амброзия икәнен дә аңламый, аңлаган очракта да аның кайда үскәнен таба алмый.

Амброзия - әремгә охшаган, артык күзгә ташланып тормый. Игътибар итсәгез, ул еш кына мәктәп ишегалларындагы клумбаларда да үсә. Амброзиянең яфраклары бәрхет гөленекенә охшаган, бакчачылар аны чәчәк дип уйлый, су сибеп үстерә...

- Бәхеткә, амброзия Татарстанда әлегә күп түгел, ул чагыштырмача сирәк очрый, - ди галим. - Республикада бу үсемлек беренче тапкыр 1987 елда табылган, популяциясе куркыныч дип әйтерлек санга җитмәгән.



### АМБРОЗИЯНЕҢ СЕРКӘЛӘРЕ – ИҢ КӨЧЛЕ АЛЛЕРГЕН

- Куакның биеклеге - 20-180 см
- Тамыры 4 метрга җитә
- Орлыктан үрчи, бер куак 40 мең орлык чәчәргә сәләтле
- Май-июнь айларында тишелеп чыга, июль азагыннан октябрьгә кадәр чәчәк ата
- Яфраклары бәрхет гөленекенә охшаган
- Торак пунктларда амброзиягә каршы көрәштә иң нәтиҗәле ысул - үскән үләнне чабып тору